| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

01.12.2021 Мәлки ав. № 11

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021елның 09 августындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021елның 09 августындагы 6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.5. пунктның 2 – 10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Регламентта дәүләт адреслы реестрын алып баруга һәм федераль мәгълүмат адреслы системасын эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Федераль мәгълүмат адреслы системасы турында һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 19 11 11 декабрендәге 1221 номерлы карары белән тәгәл туры китереп файдаланыла.»;

1.2. 1.5. пуктның 11 – 17 абзацларын 3 – 9 абзацлар дип санарга;

1.3. 2.6.1 пунктының 4 - 7 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яисә Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 2.6.1. пунктның 8 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «Башкарма комитет яисә төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. 2.6.4. пунктта «Башкарма комитетның структур бүлекчәсе» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, шулай ук Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге https://molkeev-kaybici.tatarstan.ru/веб.адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Мәлки авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Ф.П.Поляков